КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 август г.Казань № 705

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 - 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 03 февраль, 72 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 - 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 03 февраль, 72 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2020 - 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү кагыйдәләрендә:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Шәхси медицина оешмасының грантын күчерү вәкаләтле орган тарафыннан грант бирү турында килешү төзегән көннән соң 10 эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

11 пунктта «карар белән расланган» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларында шәхси медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булып торучы, шул исәптән авыл җирендә яшәүче затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2019 елның 27 декабрендәге 1915 номерлы карары белән расланган» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 - 2024 елларда Шәхси медицина оешмаларына - шәхси медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектында катнашу өчен конкурс сайлап алу җиңүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләрендә:

беренче пунктта «аларның чыгымнарын каплау» сүзләрен «чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче пунктта:

дүртенче абзацта «гамәлгә ашыру чоры» сүзләренә кадәр «чараларны» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«в) грант алучының аңа карата вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органнары тарафыннан грант бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлүен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы.»;

16 пунктның җиденче абзацында «субсидия рәвешендә» сүзләреннән соң «грант күләме» сүзләрен өстәргә;

18 пунктта:

беренче абзацта «(алга таба - грант бирү турында килешү)» сүзләреннән соң «электрон рәвештә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интегральләшкән мәгълүмат системасы юлы белән» сүзләрен өстәргә;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәхси медицина оешмасы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интегральләшкән мәгълүмат системасында грант бирү турында килешүне электрон рәвештә килешү проектын күрсәтелгән системасында урнаштырган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә имзаларга тиеш.»;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацка «шәхси медицина оешмасы гаризасы нигезендә пилот проектын гамәлгә ашыру чоры (6, 12 яисә 18 ай)» сүзләрен өстәргә;

унберенче абзацта «күрсәткечләр» сүзләрен «өчен кирәкле күрсәткечләр» сүзләренә алмаштырырга;

19 нчы пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Шәхси медицина оешмаларына күчерелә торган грант күләме, пилот проекты кысаларында хезмәт күрсәтүгә планлаштырыла торган 65 яшь һәм аннан

өлкәнрәк затлар саны шәхси медицина оешмалары тарафыннан игълан ителгән саннан чыгып, бер гражданга медицина-социаль патронажга 65 яшь һәм аннан өлкәнрәк булган бер гражданга хезмәт күрсәтүгә финанс чыгымнары нормативының бер айга, ел дәвамында медик-социаль патронаж үткәреләчәк айлар санына тапкырланган күләмдә билгеләнә.»;

23 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәхси медицина оешмасы, грант бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән пилот проектын гамәлгә ашыру чоры тәмамланган көннән алып, әлеге Кагыйдәләргә кушымта нигезендә форма буенча грант бирү турында килешүдә күрсәтелгән сынау проектын гамәлгә ашыру чоры тәмамланганнан соң җиде көн эчендә грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисапны ике нөсхәдә вәкаләтле органга тапшыра.»;

24 пунктка «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы раслаган форма буенча» сүзләрен өстәргә;

26 пунктның икенче абзацына «документлар тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау)» сүзләрен өстәргә;

27 пунктта «шәхси медицина оешмасы тарафыннан Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча, әлеге Кагыйдәләрнең өченче пунктында күрсәтелгән хезмәт күрсәтелгән 65 яшьлек һәм аннан өлкәнрәкләр һәм тормышка ашырылган чаралар саны турында хисап бирелгәннән соң җиде эш көне эчендә ай саен» сүзләрен «вәкаләтле орган тарафыннан грант бирү турында килешү төзелгән көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

28. Бирелгән грантлар вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүенең вәкаләтле органы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәсендә грант алучының әлеге Кагыйдәләрдә һәм грант бирү турындагы килешүдә билгеләнгән максатларны, шартларны һәм тәртипне сакламау билгеле булган очракта грантны күчерү өчен конкурс сайлап алуына дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирү, грант бирү нәтиҗәләренә ирешмәү очраклары ачыкланган вәкаләтле органнан тиешле таләп алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарылырга тиеш «;

күрсәтелгән Кагыйдәләргә кушымта өстәргә (карарга теркәлгән).

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин